# КАРАР

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14 ноябрь 2019 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 14 ноябрендә узган: «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә <u>191</u> кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә <u>126</u> кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы <u>119</u> кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның <u>7</u> катнашучысы тавыш бирде.

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту җибәрү белән килешәсезме?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе: Р.Х. Шәйхетдинов

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шәйхетдинов